**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**
унтугызынчы утырыш
**КАРАРЫ**

29 апрель 2022 ел **№ 123** Теләче ав.

Теләче муниципаль районы Советының 2006 елның 04 декабрендәге 59 номерлы «Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча территориаль комиссия төзү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә, социаль партнерлык яклары тәкъдимнәрен исәпкә алып, «Татарстан Республикасында социаль партнерлык органнары турында» 2004 елның 26 июлендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. «Теләче муниципаль районы буенча социаль - хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча территориаль комиссиясе» исемен түбәндәге эчтәлекле бәян итәргә: «Теләче муниципаль районында социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы территориаль комиссия».

Теләче муниципаль районында социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы территориаль комиссияне 1 номерлы кушымта нигезендә расларга.

3. Теләче муниципаль районында социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы территориаль комиссия турында Нигезләмәне яңа редакциядә 2 номерлы кушымта нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинны Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы территориаль комиссия координаторы итеп билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы территориаль комиссия секретаре функцияләрен үтәүне Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының архив эше секторы мөдире Ф.Р. Шәйхетдиновага йөкләргә.

6. Теләче муниципаль район Советының 2006 елның 04 декабрендәге 59 номерлы «Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча территория комиссиясе төзү турында» карары белән расланган социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча территориаль комиссия турында нигезләмәне үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе И.Х. Хәмидуллинга йөкләргә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы Н.Н. Хаҗипов

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советының 29.04.2022 123 нче номерлы карарына 1 номерлы кушымта

## Теләче муниципаль районында социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы территориаль комиссия составы

*Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан*

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Гайнетдинов Булат Газинур улы | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары (Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары ягының координаторы) |
| 2 | Яхин Рәис Рәшит улы | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасы рәисе |
| 3 | Павлова Лариса Петровна | МКУ «Теләче муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» җитәкчесе |

*Профсоюз ягыннан*

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Мөбинов Илдар Вакыйф улы | Теләче муниципаль районында Россия Федерациясе дәүләт учреждениеләре һәм җәмәгать хезмәте күрсәтү хезмәткәрләре һөнәри берлегенең Татарстан республика оешмасының ышанычлы заты (профсоюз ягы координаторы) |
| 2 | Фатыйхова Елена Геннадьевна | мәдәният хезмәткәрләре һөнәр берлекләренең район комитеты рәисе (килешү буенча) |
| 3 | Мөхәммәтшина Лилия Павловна | сәламәтлек саклау хезмәткәрләре профсоюзларының район комитеты рәисе (килешү буенча) |

*Эш бирүчеләр ягыннан*

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Фасхетдинов Алмаз Хәбир улы | «Алан» ҖЧҖ директоры (килешү буенча) (эш бирүчеләр ягының координаторы) |
| 2 | Якупов Рөстәм Шогаепович | «Сетевая компания» АҖ Алабуга электр челтәрләре филиалы Саба РЭЧ башлыгы (килешү буенча) |
| 3 | Ярмиев Илнур Зиннур улы | «Татавтодор» АҖ Арча филиалының Теләче юл участогы башлыгы (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 29.04.2022 ел 123 нче номерлы карарына 2 номерлы кушымта

**Теләче муниципаль районында социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы территориаль комиссия турында Нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Теләче муниципаль районында социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы территориаль комиссия турында Нигезләмә (алга таба - Комиссия) гамәлдәге законнар нигезендә территориаль һөнәри берлекләр һәм аларның берләшмәләре, эш бирүчеләрнең территориаль берләшмәләре, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкилләренең үзара килешүе нигезендә төзелә (алга таба - Комиссия яклары).

1.2. Комиссия эшчәнлегенең хокукый нигезен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Татарстан Республикасында социаль партнерлык органнары турында» 2004 елның 26 июлендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм әлеге Нигезләмә тәшкил итә.

**Комиссияне төзү принциплары һәм тәртибе**

2.1. Комиссия яклар вәкилләренең Комиссия эшчәнлегендә катнашуларының ихтыярый булуы, якларның тигез хокуклы булуы, аларның вәкилләренең тулы вәкаләтле булуы, Комиссия якларының персональ составын комиссиядә билгеләгәндә мөстәкыйльлеге һәм бәйсезлеге принциплары нигезендә төзелә.

Комиссиянең гомуми һәм персональ составы Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы тарафыннан раслана.

Территориаль һөнәри берлекләр һәм аларның берләшмәләре, эш бирүчеләрнең территориаль берләшмәләре үз вәкилләрен Комиссия составына җибәрергә хокуклы.

Комиссия яклары вәкилләре Комиссия әгъзалары булып тора. Комиссиянең һәр ягыннан әгъзасы саны тигез һәм 10 кешедән арта алмый.

2.2. Территория һөнәри берлекләре һәм аларның берләшмәләре, эш бирүчеләрнең территориаль берләшмәләре вәкилләрен комиссиягә раслау һәм алмаштыру шушы берләшмәләр органнары карары белән гамәлгә ашырыла.

2.3. Җирле үзидарә органнары вәкилләрен раслау һәм алмаштыру тиешле җирле үзидарә органы карары белән башкарыла.

**3. Комиссиянең максатлары һәм бурычлары**

3.1. Комиссиянең төп максатлары түбәндәгеләр:

- социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу һәм якларның социаль-икътисадый мәнфәгатьләрен килештерү;

- социаль партнерлык системасын үстерү;

- күмәк хезмәт бәхәсләрен (конфликтларны) җайга салуга ярдәм итү.

3.2. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- күмәк сөйләшүләр алып бару һәм территориаль килешү проектын әзерләү;

- территориаль килешүне үтәү барышында барлыкка килгән Комиссия яклары инициативасы буенча мәсьәләләрне карау;

- территориаль дәрәҗәдә социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен шартнамәчел җайга салуга ярдәм итү;

- социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре, хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү, социаль тәэмин итү өлкәсендә территориаль программалар проектларын эшләүгә бәйле мәсьәләләр буенча консультацияләр уздыру;

- территориаль килешүнең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру, аны үтәү барышында барлыкка килгән каршылыкларны хәл итү, шулай ук ризалыкка ирешмәгән мәсьәләләрне җайга салу.

## 4. Комиссиянең хокуклары

4.1. Комиссия хокуклы:

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының икътисадый һәм социаль үсеш мәсьәләләре буенча комиссия якларының эшчәнлеген координацияләргә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында төзелә торган тармак килешүләрен төзегәндә барлыкка килә торган каршылыкларны җайга салырга;

- территориаль килешүне эшләгәндә, гамәлгә ашырганда һәм Комиссия карарларын үтәгәндә, Комиссия яклары мәнфәгатьләрен килештерергә;

- күмәк сөйләшүләр барышында һәм территориаль килешү проектын әзерләү барышында социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча Республика өчьяклы комиссиясе, тармак комиссияләре, социаль партнерлыкның башка органнары белән хезмәттәшлек итәргә;

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының социаль-икътисадый хәле турында Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында төзелә торган тармак килешүләре комиссиясе утырышында карала торган территориаль килешүне үтәү һәм каршылыкларны җайга салу мәсьәләләрен карау өчен кирәкле мәгълүматны алырга;

- Комиссия әгъзасы булмаган экспертларны, галимнәрне һәм белгечләрне, башка оешмалар вәкилләрен үз эшчәнлекләрендә катнашу өчен экспертлар, галимнәр һәм белгечләр җәлеп итеп эшче төркемнәр оештырырга;

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының җирле үзидарә органнары уздыра торган утырышларда профсоюзлар һәм эш бирүчеләр вәкилләре катнашында социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен һәм аларга турыдан-туры бәйле икътисадый мөнәсәбәтләрне җайга салу мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр кертергә;

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының җирле үзидарә органнары уздыра торган утырышларда катнашу өчен, шулай ук әлеге органнар

тарафыннан төзелгән комиссияләр эшендә катнашу өчен үз вәкилләрен җибәрергә;

- закон нигезендә территориаль килешү проектын әзерләү һәм төзү тәртибен, территориаль килешү төзүдә катнашмаган эш бирүчеләрне кушу тәртибен законнар нигезендә билгеләргә;

- ;Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының җирле үзидарә органнары, территориаль һөнәри берлекләр һәм аларның берләшмәләре, эш бирүчеләрнең территориаль берләшмәләре тарафыннан комиссиягә тәкъдим ителгән мәсьәләләр буенча мәҗбүри булган Комиссия компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча карарлар кабул итәргә;

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге норматив-хокукый актларын эшләүдә катнашырга;

- Комиссия карарларының үтәлешен тикшереп торырга.

4.2. Комиссия Комиссия регламентын эшли һәм раслый.

## 5. Комиссия координаторы

5.1. Комиссия координаторы, Комиссия якларының тәкъдимнәрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы тарафыннан билгеләнә. Координатор Комиссия әгъзасы түгел булып тормый.

5.2. Комиссия координаторы:

- Комиссия эшчәнлеген якларның координаторлары белән берлектә оештыра, утырышларда рәислек итә;

- Комиссиянең эш планнарын һәм карарларын имзалый;

- якларның позицияләрен килештерүдә, уртак карарлар чыгарганда һәм аларны гамәлгә ашырганда килешүгә ирешүдә ярдәм итә;

- Комиссия секретариаты эше белән җитәкчелек итә;

- Комиссия эшендә Комиссия әгъзасы булмаган территориаль һөнәри берлекләр һәм аларның берләшмәләре, эш бирүчеләрнең территориаль берләшмәләре һәм җирле үзидарә органнары вәкилләрен, шулай ук галимнәрне һәм белгечләрне, башка оешмалар вәкилләрен чакыра;

- территориаль һөнәр берлекләре, эш бирүчеләрнең Территориаль берләшмәләре һәм җирле үзидарә органнары белән килештереп, әлеге берләшмәләр һәм органнар тарафыннан үткәрелә торган утырышларда катнашу өчен комиссия әгъзаларын җибәрә, аларда социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу белән бәйле мәсьәләләр карала;

- үз компетенциясе кысаларында комиссия утырышлары арасында оператив карарлар кабул итүне таләп итә торган мәсьәләләр буенча якларның координаторлары белән консультацияләр үткәрә;

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советына Комиссия эшчәнлеге турында хәбәр итә;

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендә күрелә торган чаралар турында комиссиягә хәбәр итә.

5.3. Комиссия координаторы яклар эшчәнлегенә тыкшынмый һәм тавыш бирүдә катнашмый.

## 6. Комиссия эшчәнлеген оештыру һәм карарлар кабул итү тәртибе

6.1. Комиссия үз эшчәнлеген яклар тарафыннан имзаланган һәм комиссиянең чираттагы елга эш планы белән расланган яклар тәкъдимнәрен исәпкә алып формалаштырыла торган (алга таба – Комиссия эш планы) нигездә башкара.

Комиссия утырышлары Комиссиянең эш планы нигезендә уздырыла.

Комиссия утырышлары арасында оператив карарлар кабул итүне таләп иткән мәсьәләләр буенча Комиссия координаторы яклар вәкилләре белән консультацияләр үткәрә. Бу очракта чираттан тыш карау өчен сораулар тәкъдим иткән як ике атна дәвамында утырыш уздыру өчен материаллар әзерләүне тәэмин итә (кертелә торган мәсьәләләр буенча мәгълүмат, карар проекты һ.б.).

6.2. Комиссия утырышы утырышта һәр якның кимендә 2/3 составы катнашса, хокуклы дип санала.

Комиссия тарафыннан утырышларда карала торган барлык мәсьәләләр буенча карарлар Комиссиянең һәр якны тәкъдим итүче әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия кабул иткән карарлар һәр якка үтәү өчен мәҗбүри.

Кабул ителгән карар белән килешмәгән Комиссия әгъзалары аларның аерым фикерен Комиссия утырышы беркетмәсенә кертүне таләп итәргә хокуклы.

6.3. Комиссия эшчәнлеген оештыру һәм финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.4. Комиссия эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итү өчен Комиссия тарафыннанраслана торган 3 кеше күләмендә секретариат төзелә. Комиссия координаторы секретариат эше белән җитәкчелек итә.

6.5. Комиссия секретариаты:

- Комиссия утырышларында карау өчен материаллар әзерләүне тәэмин итә;
- Теләче муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан, территориаль профсоюз оешмаларыннан һәм аларның берләшмәләреннән, эш бирүчеләрнең территориаль берләшмәләреннән Комиссия утырышларында каралырга тиешле мәсьәләләр буенча мәгълүмат соратып ала;
- Комиссия карарларын Теләче муниципаль районының җирле үзидарә органнарына, территориаль һөнәр берлекләре оешмаларына һәм аларның берләшмәләренә, эш бирүчеләрнең территориаль берләшмәләренә үтәү өчен җибәрә;
- эшлекле җитештерүне алып бара һәм Комиссия документлары белән эшне оештыра.

6.6. Комиссия утырышлары Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында уздырыла, утырыш кирәк булган очракларда башка биналарда (бүлмәләрдә) уздырыла.